**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге составына керүче Алексеевка авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

23 ноябрь 2025 ел № 3

2025 елның 20 мартындагы 33 номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлеге Советы ««Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»05.11.2019 ел №102 карары нигезендә, «Гражданнарның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү акчаларын җәлеп итүгә бәйле җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән түбәндәге сорау буенча 2025 ел 20 ноябрендә узган җыен нәтиҗәләре беркетмәсе тәзелде:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Алексеевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

***1.Җирлекнең халык яшәгән пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.***

*- Беловка авыл җирлеге* Алексеевка *торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау.(Беловка авыл җирлеге* Алексеевка *торак пункты чикләрендә юлны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр һәм җайланмалар сатып алу; эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, поселок юлларын ремонтлау, вак таш кайтару, туфрак һәм вак таш салу һәм тигезләү).*

**2.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлектә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Алексеевка авылында суүткәргеч челтәрен ремонтлау, материаллар сатып алу, тирәнлек насосын ремонтлау һәм алыштыру, шартнамә, эксплуатация чыгымнарын түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 72 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 39 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Риза»- 39 катнашучы тавыш бирде;
- «Каршы» - 0 катнашучы тавыш бирде;
- «Тыелдым»-0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге составына керүче Алексеевка торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

Мәсьәлә буенча карарны кабул дип танырга:: «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Алексеевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

***1.Җирлекнең халык яшәгән пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.***

*- Беловка авыл җирлеге* Алексеевка *торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау.(Беловка авыл җирлеге* Алексеевка *торак пункты чикләрендә юлны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр һәм җайланмалар сатып алу; эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, поселок юлларын ремонтлау, вак таш кайтару, туфрак һәм вак таш салу һәм тигезләү).*

**2.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлектә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Алексеевка авылында сууткәргеч челтәрен ремонтлау, материаллар сатып алу, тирәнлек насосын ремонтлау һәм алыштыру, шартнамә, эксплуатация чыгымнарын түләү).

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

И.Р.Мәхмүтов